Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының унберенче утырышы

# КАРАР

22 октябрь, 2021 ел — № 29

«Җир салымы турында» 2017 елның 09 октябрендәге 41 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. «Җир салымы турында» 2017 елның 09 октябрендәге 41 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.1. Җир кишәрлеге бер төрдән артык рөхсәт ителгән файдалануга ия булса, салым салу максатларында әлеге кишәрлек өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төрләре буенча җир салымы ставкасының иң зур күләме «Җир салымы турында» авыл җирлеге карары белән билгеләнгән булуын билгеләргә.».

2. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткергә).

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы — А.Р.Сәйфетдинов